ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.17, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 17 йорт, Акбаш авылы, 423958

Тел./факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№13** **«15» октябрь 2025 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 11 октябрендәге 8 санлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2025 елның 20 мартындагы "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ санлы Федераль закон, 2022 елның 28 февралендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»гы 175 санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. 1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 11 октябрендәге 8 санлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Административ регламентның 2.5 бүлегендәге 2.5.1 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү

кирәк булган очракта һәм федераль закон нигезендә мондый шәхси күрсәткечләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, Муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртүгә ризалыгын алуын раслый торган өстәмә документлар тапшыра. Ризалык алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru/ һәм "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" челтәр басмасында Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru (2013 елның 17 декабрендәге Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын урнаштыру адресы буенча http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р.Сәхибуллина